КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 июнь г.Казань № 613

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 ноябрь, 1078 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» гранты турындагы нигезләмәдә:

6 пунктның дүртенче абзацында «һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органы», «максатлар,» сүзләрен төшереп калдырырга, «шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алучының Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерү өлешендә;» сүзләрен өстәргә»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Министрлык сайлап алуны үткәрү башланганчы 30 календарь көннән дә соңга калмыйча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм үзенең рәсми сайтында сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

әлеге Нигезләмәнең 21 пункты нигезендә грант бирү нәтиҗәсе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

әлеге Нигезләмәнең 10 пункты һәм грант алырга дәгъва кылучы тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге нигезендә грант алырга дәгъва кылучыларга карата таләпләр;

гаризалар бирү тәртибе һәм бу Тәртипнең 13 пункты нигезендә бирелә торган гаризалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Нигезләмәнең 14 - 19 пунктлары нигезендә заявкаларны карау һәм бәяләү кагыйдәләрен;

грант алырга дәгъва кылучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану вакыты;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан грант бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм Вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы, ул сайлап алу җиңүчеләрен билгеләгән көненнән соң килүче 14 календарь көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын.»;

23 пунктта:

бишенче абзацта «нәтиҗәләре» сүзен «нәтиҗәнең мәгънәсе» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «максатлар,» сүзен төшереп калдырырга;

25 пунктта «нәтиҗәләре» сүзен «нәтиҗәнең мәгънәсе» сүзләренә алмаштырырга;

27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Министрлык грантлар бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, грант алучы тарафыннан үтәлешен тикшерүне, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыра.

Грант бирүнең нәтиҗәсенә ирешү мониторингын үткәрү, килешү белән билгеләнгән грант бирү нәтиҗәсенең һәм грант (контроль нокта) бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле проектны тәмамлау фактын чагылдыра торган вакыйгаларның күрсәткечләренә ирешүдән чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләр буенча мониторинг үткәрелә.».

30 пунктта «максатлар» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган «Безнең иң яхшы методист» гранты турындагы нигезләмәдә:

3 пунктның өченче – дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә тапшырылган белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы, белгечлеге буенча кимендә өч ел практик эш стажы яисә белем бирү оешмасында кимендә 10 ел педагогик стажы булган  Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең мәгариф идарәләренең (бүлекләренең) мәгълүмат-методика бүлекләренең методистлары, өлкән методистлары;

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә тапшырылган белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы, белгечлеге буенча кимендә өч ел практик эш стажы булган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең мәгариф идарәләренең (бүлекләренең) мәгълүмат-методика бүлекләренең җитәкчеләре;»;

4 пунктның өченче – дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең мәгариф идарәләренең (бүлекләренең) мәгълүмат-методика бүлекләре җитәкчеләре арасыннан грант алучылар – 100,0 мең сум;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең мәгариф идарәләренең (бүлекләренең) мәгълүмат-методика бүлекләренең методистлары, өлкән методистлары арасыннан грант алучылар – 130,0 мең сум.»;

5 пунктта:

икенче абзацта «бүлекләр (идарәләр) методистлары» сүзләрен «идарәләрнең (бүлекләрнең) мәгълүмати-методик бүлекләренең методистлары, өлкән методистлары» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «бүлек (идарәләр) башлыклары урынбасарлары» сүзләрен «идарәләрнең (бүлекләрнең) мәгълүмат-методика бүлекләре җитәкчеләре» сүзләренә алмаштырырга, «укыту-методик эш буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктта «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең  мәгариф бүлекләренең  (идарәләренең) укыту-методик эш буенча методистлары, башлыклары урынбасарлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең мәгариф идарәләренең (бүлекләренең) мәгълүмати-методик бүлекләре  җитәкчеләре, методистлары, өлкән методистлары» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында муниципаль методик хезмәтне үстерүгә юнәлдерелгән проектны гамәлгә ашыру.»;

10 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында муниципаль методик хезмәтне үстерүгә юнәлдерелгән проект.»;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә, әлеге карарның  2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктының егерме бишенче абзацыннан тыш.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 елның 13 августындагы 708 номерлы карары белән расланган «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» гранты турындагы нигезләмәнең 10 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин